# МИГРАНТ-ЯЗУЧЫЛАР ИҖАТЫНДА МӘДӘНИЯТАРА ДИАЛОГ (А.ГӘРӘЕВА-АКЧУРА ИҖАТЫ МИСАЛЫНДА)

**Каюмова Гелюся Фаридовна**,
*доцент кафедры татарской литературы института филологии и межкультурной коммуникации,*
*Казанский Федеральный университет,*
*г. Казань, Россия,*
*gulfar21@mail.ru*

***Аннотация:*** *Мультикультурализм – ключевой показатель современности. Экономика, промышленность, культура, система образования-названные и многие другие сферы развиваются и изменяются в мультикультурных условиях. Мультикультурализм оказал своеобразное влияние на развитие татарской литературы. А. Гареева-Акчура-автор, живущий в условиях татарской и турецкой культуры. В его творчестве отражены татаро-турецкие контакты, их исторические основы, общие и самобытные стороны национальных моделей.*

***Ключевые слова:*** *Айзиряк Гараева Акчура, татарская литература, национальная культурная модель, аккультурация, мультикультурный мир, писатель-мигрант.*

***Abstract:*** *Multiculturalism is a key indicator of modernity. Economy, industry, culture, education system -these and many other areas are developing and changing in multicultural conditions. Multiculturalism had a peculiar influence on the development of Tatar literature. A. Gareeva-Akchura is an author living in the conditions of Tatar and Turkish culture. His work reflects Tatar-Turkish contacts, their historical foundations, common and original sides of national models.*

***Keywords:*** *Aiziryak Garayeva Akchura, Tatar literature, national cultural model, acculturation, multicultural world, migrant writer.*

Мультимәдәнилек – бүгенге заманның төп күрсәткече. Икътисад, сәнәгать, мәдәният, мәгариф системасы – аталган һәм күп кенә башка өлкәләр мультимәдәни шартларда үсеш һәм үзгәреш кичерә. Күпмәдәнилелек татар әдәбияты үсешенә үзенчәлекле йогынты ясый. Бер яктан, көнбатыш, рус әдәбиятлары йогынтысында татар әдәбиятында да массакүләм мәдәнияткә борылыш ясала, халык кызыксынып укый торган детектив (Т. Галиуллин һ.б.), фэнтези һәм хоррор (М. Кәбиров) кебек жанрларга мөрәҗәгать итү күзәтелә. Әмма бу һ.б. авторлар шушы әсәрләрдә дә милли-мәдәни, җитди иҗтимагый, гомумкешелек өчен хас проблемаларны укучы алдына бастырырга, алар хакында уйланырга, проблемаларның кайбер чишү юлларын тәкъдим итәләр. Мультимәдәни дөньяда үсеш кичерүче әдәбиятның мөһим өлешен эмиграциядәге әдипләр иҗаты тәшкил итә. Галимнәр ассызыклавы буенча, “яңа, мультикультур дөньяның реалияләрен раслауда язучы-мигрантлар зур роль

уйный. Болар – теге яки бу сәбәпләр аркасында мәдәни тирәлекләрен кисәк алмаштырырга мәҗбүр булган, яңа шартларда еш кына аккультурация, ягъни мәдәниятләрнең тәэсир итешүе, икенче мәдәният кыйммәтләрен кабул итүнең шактый авыр, катлаулы процессны иҗади аңнары аша үткәрергә тиеш булган язучылар” [Толкачев 2013]. Бу яктан Айзирәк Гәрәева-Акчура иҗатын типик дип әйтеп булмый: аларда туган, газиз мәдәниятне сагынып искә алу, аннан ераклашуга ачыну, яңа мәдәниятне калеб белән кабул итә алмау шикелле психологик кичерешләр юк дияргә була. Дөрес, “Гаҗизлек” кебек әсәрендә автор геройларының гаять катлаулы кичерешләрен тасвирлый, әмма болар чит ил культурасын кабул итү авырлыгы белән түгел, ә башка факторлар белән аңлатыла. Әсәр геройлары – Ватанны яклап сугышканда әсирлеккә эләккән, төрле юллар белән газаплы әсирлектән котылган, Төркиядә сыеныр урын тапкан солдатлар. Туган якларына кайткан очракта аларны НКВД органнары, шпионлыкта гаепләнү, дистә елларга сузылган лагерь тормышы көтәр иде. Алар, Төркиягә китеп, шушы газаптан котылсалар да, туганнары, якыннары өчен борчылу утында яналар. Шуңа күрә ялгызлары калдымы, алар бертуктаусыз Ходайга ялваралар, якыннарының тормышын саклауларын Илаһи көчтән үтенәләр; кеше алдында елмаеп йөрсәләр дә, аулакта яшь түгәләр. Бүгенге заман күзлегеннән караганда исә, А. Гәрәева-Акчура фикеренчә, татар милли моделе буенча яшәүчегә Төркиядәге тормышка иялэшү катлаулы түгел. Боларны ул үз тормышы мисалында кат-кат раслый.

2019 елда “Казан утлары” басмасында А. Гәрәева-Акчураның “Ике әни” очеркы басылып чыкты. Очерк ике мәдәният – татар һәм төрки мәдәниятен чагыштыру, аралагы охшашлыкларны ассызыклауга багышлана. Язучы моның өчен үзенчәлекле алым – татар хатыны – үз әнисе Вәсилә апаның һәм төрек иренең әнисе – бианасы Әминә апаларның язмышын чагыштыра. Әмма биредә шуңа да игътибар итәргә кирәк: Әминә ханым да Төркиягә Татарстаннан күченгән нәселдән: “1890 нчы еллар... Рус патшасының «мөселманнар теләгән өлкәгә күченә алырлар» дигән бер бик кыска вакытлы фәрманын Шахи мулла отып ала. Нәселләре 30 ел гомер кичергән Акманнан Госманлы иленә мөһаҗирлеккә китәргә карар итә, паспорт юнәтә...” [Гәрәева-Акчура 2019: 162]. Әмма әсәрдә сурәтләнү вакытында ул инде тулысы белән төрек мәдәнияте, төрек кануннары, төрек кыйммәтләре буенча яшәүче герой буларак тасвирлана. Шул ук вакытта мондый геройлар төрек мәдәнияте турындагы стереотипик фикерләрдән арынырга, һичьюгы, башка милләт яшәеше турындагы белемнәрне тирәнәйтергә ярдәм итә. Төркиягә килгәнче миңа, ни өчендер, төрекләр

һәрвакыт, һәркайда каһвә генә эчеп йөриләрдер кебек иде. Төрек каһвәсе бөтен дөньяга танылган, мактаулы бренд булганга күрәдер, күңелдә сиздермәстән шундый бер ышану барлыкка килгән. Чыннан да, Төркиядә кая барсаң да, бармак очы кадәр кечкенә филҗанга ясалган һәм бер бокал гадәти су белән эчелә торган әче төрек каһвәсен еш тәкъдим итәләр. Әмма бу ил миңа әнинең юкә чәе белән бергә бөтенләй башка яктан ачылды”, – дип яза автор. Гади бер деталь – һава алмашыну сәбәпле үзен бик үк яхшы хис итмәгән кешене юкә чәчәге чәе белән сыйлау, шуның шифасына ышану – татар һәм төрки мәдәниятләренең охшаш ягы, ярдәмчеллек, табигатьне якын итү һәм аның байлыгы белән урынлы файдалану, шуның өчен рәхмәтле була белү кебек якларын ача.

А. Гәрәева-Акчура әсәрләрендә тагын бер кыйммәтле һәм мультикультур дөньяда әһәмияткә ия булган фикер әйтелә: һәр милләтнең бүгенгесе үткән тарих белән тыгыз бәйләнгән. Язмыш кешене башка мәмләкәткә китереп ташлый икән, син шушы мәмләкәттә яшәүчеләрнең телен генә түгел, тарихын да белергә тиеш. “Өченче көнне җыелышкач та, авыл халкы тарих сәхифәләрен яңартты. Болар сөйләнгәндә, мохтар беркемне бүлми тыныч кына утырды. Әгәр мосафирлар кире Татарстанга кайта алмаса, аларга шушы җирдә яшәргә кирәк булачак. Ә җирлек тарихын белмичә анда ничек яшисең?!”– дип яза ул “Гаҗизлек” әсәрендә [Гәрәева-Акчура 2020: 123].

Аңлашылганча, А. Гәрәева-Акчура иҗатында төрки-татар мәдәниятләренең тыгыз бәйләнышлары нәтиҗәсендә аларның бер-берсен йота алмаулары, киресенчә, бер-берләренә якын торулары ассызыклана. Болар, әлбәттә, беренче чиратта, мәдәни модельләрнең (телләр кардәшлеге, дин уртаклыгы, менталитет якынлыгы) охшаш яклары күп булу белән билгеләнә, тарихның фаҗигале елларында Төркиянең күп кенә татарлар өчен сыену урыны булуы, димәк, электән татарларның төрки мәдәнияте белән якыннан таныш булуы, шул ук вакытта милли идентификацияне саклап калу омтылышы (бу бигрәк тә “Ике әни” очеркында Әминә апа нәселенең Төркиягә күчеп, авыл кору өчен җир сайлавы тарихында ачык күренә) бүгенге глобаль дөньяда төрки-татар багланыш, элемтәләренең нәтиҗәлелеге өчен алшарт булып тора. Әлбәттә, сүз ике милләт моделенең тәңгәллеге турында сүз бармый, төрекләр һәм татарлар төрле тарихи юл үтәләр. Галимнәрнең, мәсәлән, Ә.Т. Сибгатуллина хезмәтләрендә бер үк иҗтимагый-сәяси юнәлешкә юл тоту, мәсәлән, европалашу тенденциясенең төрек һәм татар әдәбиятында төрлечә яктыртылуы, милли (төрек, татар) геройларның европа (рус) мәдәниятен кабул итүдә уртак

һәм аермалы яклары булу, аларны бу мәдәнияткә якынаерга мәҗбүр итүче күчләрнең төрле булуы, европа мәдәниятен йөртүче геройларның милли (төрек, татар) мәдәнияткә мөнәсәбәтләре төрлелеге ассызыклана [Сибгатуллина 2017: 244-263].

А.Гәрәева-Акчура – татар һәм төрек мәдәнияте шартларында яшәүче автор. Аның иҗатында татар-төрек бәйләнешләре, аларның тарихи нигезләре, милли модельләрнең уртак һәм үзенчәлекле яклары сурәтләнә, төрки мохиттә татар милләте идентификациясен саклап калган, шул ук вакытта төрки милли моделен дә кабул итә алган геройлар, шул исәптән автор образы әдибә иҗатының даими игътибар үзәген тәшкил итәләр. Мультимәдәни дөнья шартларында мондый геройлар милли үзаңны саклап калу, башка мәдәниятләргә ихтирамлы караштa тору үрнәге буларак кабул ителә ала.

**Әдәбият исемлеге:**

1. Гәрәева-Акчура А. Ике әни (очерк) // Казан утлары. – 2019. – №11. – Б.158-163.
2. Гәрәева-Акчура А. Гаҗизлек (хикәя) // Казан утлары. – 2020. – №8. – Б.118-147.
3. Сибгатуллина А.Т. Поиск идентичности в татарской и турецкой литературах в контексте “Восток-Запад” на рубеже XIX-XX веков // STUDIA LITTERARUM. – 2017. – т.2. – №2. – С.244-263.
4. Толкачев С.П. Мультикультурализм в постколониальном пространстве и кросс-культурная английская литература. Информационно-гуманитарный портал «Знание. Понимание. Умение». 2013. №1 (январь-февраль) – URL: http://www.zpu-journal.ru/e-zpu/2013/1/Tolkachev_Multiculturalism-Cross-cultural-Literature/; мөрәҗәгать итү вакыты: 15.09.2021.